БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
17 декабрь 2025 ел

**КАРАР**
№ 28

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең чикләре турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы», «Норма авыл җирлеге», «Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү (карта-схема кушымтада бирелә), шулай ук Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керә торган «Куныр авыл җирлеге», «Нөнәгәр авыл җирлеге», «Пыжмара авыл җирлеге», «Смәел авыл җирлеге», «Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең чикләрен Татарстан Республикасы чикләренә туры китерү инициативасы белән чыгарга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына тиешле муниципаль берәмлекләрнең чикләре буенча тәкъдим ителә торган үзгәрешләр буенча фикерләрен белдерүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге һәм Норма, Сосна, Куныр, Смәел, Шеңшеңәр, Нөнәгәр, Пыжмара авыл җирлекләренең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе

Р.Р.Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2025 елның 17 декабрендәге
28 номерлы карарына кушымта

# КАРТА-СХЕМА

